ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ АКХУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

15 февраль 2019 ел №90

Югары Акхуҗа авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында гражданнар һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Акхуҗа авыл җирлеге Советы карар итә:

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Акхуҗа авыл җирлеге Советының 2016 елның 15 апрелендәге 20 номерлы “җирле үзидарә органнарында гражданнар һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында” карары белән расланган Югары Акхуҗа авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында гражданнар һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 4.8 пунктта. "миграция өлкәсендә хокук куллану функцияләрен, контроль, күзәтчелек һәм дәүләт хезмәтләрен күрсәтү функцияләрен гамәлгә ашыра торган башкарма хакимиятнең федераль органының территориаль органы" сүзләрен «эчке эшләр өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органы территориаль органы» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. 5.1 пунктта «яки почта адресы» сүзләрен «яки адресны (почта адресы яки электрон почта адресы)» сүзләренә алыштырырга;

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Югары Акхуҗа авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Югары Акхуҗа авыл җирлеге башлыгы З.Я.Юзеев